КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 октябрь г.Казань № 1239

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга, шулай ук федераль бюджеттан финанслана торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алуга һәм аларны сәнәгать эксплуатациясенә кертүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы; 2023 ел, 9 август, 961 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга, шулай ук

федераль бюджеттан финанслана торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алуга һәм аларны сәнәгать эксплуатациясенә кертүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) һәм агросәнәгать комплексы объектларын төзүне һәм (яисә) модернизацияләүне гамәлгә ашыручы Россия оешмалары тарафыннан агросәнәгать комплексының реализацияләнә торган объектлары буенча турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 549 номерлы» сүзләрен «Акча алучылар тарафыннан реализацияләнә торган объектлар буенча турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелгән инвестиция проектларын, шулай ук акча алучылар тарафыннан маркировка җиһазлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелгән маркировка җиһазлары сатып алу чыгымнарын каплауга заявкаларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибен раслау турында» 2023 елның 23 июнендәге 587 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) һәм агросәнәгать комплексы объектларын төзүне һәм (яисә) модернизацияләүне гамәлгә ашыручы Россия оешмалары тарафыннан агросәнәгать комплексының реализацияләнә торган объектлары буенча турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 ноябрендәге 549 номерлы» сүзләрен «Акча алучылар тарафыннан реализацияләнә торган объектлар буенча турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелгән инвестиция проектларын, шулай ук акча алучылар тарафыннан маркировка җиһазлары сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелгән маркировка җиһазлары сатып алу чыгымнарын каплауга заявкаларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибен раслау турында» 2023 елның 23 июнендәге 587 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин